СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 08 » ноябрь 2024 ел** **№ 308**

**«Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү һәм торак урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2006 елның 28 июнендәге 74 номерлы Арча район Советы карарына үзгәрешләр кертү турында (22.02.2013 N 197 үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон, Арча муниципаль районы Уставы нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. «Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү һәм торак урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2006 елның 28 июнендәге 74 номерлы Татарстан Республикасы Арча район Советы карарына (22.02.2013 N197 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү турындагы нигезләмәдә (1 нче кушымта):

1) 6.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.8. Торак яисә торак булмаган урын буларак файдалануны тәэмин итү өчен аны үзгәртеп кору, һәм (яисә) яңадан планлаштыру, һәм (яисә) башка эшләр башкару таләп ителмәгән очракта, Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясындагы 5 өлешендә каралган, торак урынны торак булмаган урынга яисә торак булмаган урынны торак урынга күчерү турында карар кабул ителүне раслый торган документтагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү өчен нигез булып Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры тора. Бу очракта күрсәтелгән күчерү мондый бинаның билгеләнеше турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән тәмамланган дип санала.»;

2) 7.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.11. Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясындагы 8 өлешендә күрсәтелгән үзгәртеп корулар, һәм (яисә) яңадан планлаштыру, һәм (яисә) башка эшләр тәмамланганнан соң, мөрәҗәгать итүче күчерелә торган бинаның урнашкан урыны буенча турыдан-туры яки күпфункцияле үзәк аша алар тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үзара хезмәттәшлек турында төзелгән килешү нигезендә күрсәтелгән үзгәртеп коруның, һәм (яисә)

яңадан планлаштыруның, һәм (яисә) башка эшләрнең тәмамлануы турында хәбәрнамәне биналарны күчерүне гамәлгә ашыручы органга җибәрә. Бинаны яңадан планлаштырган очракта, мондый хәбәрнамәгә бинаның «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнгән техник планы кушып бирелә. Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясындагы 8 өлешендә күрсәтелгән үзгәртеп кору, (яисә) яңадан планлаштыру һәм (яисә) башка эшләрнең тәмамлануы биналарны күчерүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан төзелгән кабул итү комиссиясе акты (алга таба - кабул итү комиссиясе акты) белән раслана. Кабул итү комиссиясе актын раслау биналарны күчерүче орган әлеге өлештә күрсәтелгән хәбәрнамәне алган көннән алып утыз көннән дә артмаган вакытта гамәлгә ашырыла. Торак урынны торак булмаган урынга яисә торак булмаган урынны торак урынга күчерү турында карар кабул итүне раслый торган документ нигезендә үзгәртеп кору һәм (яисә) башка эшләр башкару таләп ителгән торак булмаган урынны торак урынга күчерү турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә үзгәрешләр кертелгән көннән төгәлләнгән дип санала. Торак урынны торак булмаган урынга яисә торак булмаган урынны торак урынга күчерү турында карар кабул итүне раслый торган документ нигезендә мондый бинаның чикләре һәм (яисә) мәйданы һәм билгеләнеше яисә төзелгән биналарны дәүләт кадастр исәбенә алу һәм барлыкка килгән биналарга хокукны дәүләт теркәвенә алу турында бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә үзгәрешләр кертелгән көннән алып яңадан планлаштыру таләп ителгән торак урынга күчерү тәмамланган дип санала.».

1.2. «Торак урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру турында» нигезләмәдә (2 нче кушымта):

1) 3.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10. Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны тәмамлау:

1) күпфатирлы йорттагы урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру тәмамлангач, мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясындагы 9 өлешендә каралган ысул белән килештерүне гамәлгә ашыручы органга күрсәтелгән эшләрнең тәмамлануы турында хәбәрнамә җибәрә. Бинаны яңадан планлаштырган очракта, мондый хәбәрнамәгә мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнгән яңадан планлаштырылган бинаның техник планы кушып бирелә. Бинаны яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә яңа урыннар барлыкка килгән очракта, бинаны яңадан планлаштыруның тәмамлануы турындагы хәбәрнамәдә мөрәҗәгать итүченең күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алуга дәүләт пошлинасын түләве турындагы белешмәләр күрсәтелә.

2) күпфатирлы йортта урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру кабул итү комиссиясе акты белән раслана, аны раслау биналарны күчерүне гамәлгә ашыручы орган әлеге статьяның 1 өлешендә каралган хәбәрнамә алган көннән алып утыз көннән дә артмаган вакытта гамәлгә ашырыла.

3) күпфатирлы йортта урынны үзгәртеп кору Россия Федерациясе Торак

кодексының 28 статьясындагы 2 өлешендә каралган актны раслаган көннән төгәлләнгән дип санала. Күпфатирлы йортта урынны яңадан планлаштыру бинаның чикләре һәм (яисә) мәйданы яисә төзелгән биналарны дәүләт кадастр исәбенә алуны гамәлгә ашыру һәм барлыкка килгән биналарга хокукны дәүләт теркәвенә алу турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә үзгәрешләр кертелгән көннән төгәлләнгән дип санала.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев